УДК 811

# КАВИ НӘҖМИ ИҖАТЫНДА РЕВОЛЮЦИЯ ТЕМАСЫ

# ТЕМА РЕВОЛЮЦИИ В ТВОРЧЕСТВЕ КАВИ НАДЖМИ

**Ахметшина Айгуль Дамировна, Шаймарданова Люция Шарифзяновна**
Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение «Мамадышский политехнический колледж», г. Мамадыш, Российская Федерация; Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Елабуга, Российская Федерация
*e-mail: aigulkabelekez@mail.ru*

**Аннотация.** Кави Наджми – один из известных писателей и поэтов татарского народа. Известный как “революционный певец” свой первый творческий шаг Кави Наджми делает на стороне рабоче-крестьянской власти. Он искренне верит в социалистическую идею, как человек верующий, ставит себя на стороне борьбы за счастье народа. Как писатель борьба за свободу и социализм в творчестве писателя-главная тема всей истории татарского народа.
**Ключевые слова:** Революция, борьба, личность, свобода, новые идеи.

# REVOLUTION SUBJECT IN KAVI NADZHMI'S CREATIVITY

**Akhmetshina Aygul Damirovna; Shaymardanova Lucia Scharifsjanowna**
Public autonomous professional educational institution "Mamadyshsky Polytechnical College", Mr. Mamadysh, Russian Federation; Yelabuga institute of the Kazan (Volga) federal university, Yelabuga, Russian Federation

**Abstract.** Kavi Nadzhmi – one of the famous writers and poets of the Tatar people. Known as "the revolutionary singer" Kavi Nadzhmi takes the first creative step on the party of the Workers' and Peasants' power. He sincerely believes in the socialist idea as the person the believer, puts himself on the party of fight for happiness of the people. As the writer fight for freedom and socialism in works of the writer - the main subject of all history of the Tatar people.

**Keywords:** Revolution, fight, personality, freedom, new ideas.

Кави Нәҗминең “Язгы җилләр” исемле тарихи-революцион романы бик озак һәм күп көч салып эшләнгән иң төп әсәре булып тора. Әлеге роман, татар халкының инкыйлаби үзгәрешләр чорындагы тарихи язмышын, халык массаларының патша империясенә каршын, алып барган көрәшен, совет хакимиятенең рәсми идеологиясе таләпләре һәм заманның сәяси вәзгыяте яссылыгында анализланса да, тарихи чынбарлыкның төп күренешләрен, вакыйгаларын, халыкның тормышын, гореф-гадәтләрен, әсәрдәге төп каһарманнарның холык үзенчәлекләрен, эш-гамәлләрен сәнгатьчә сурәтли.

Романдагы вакыйгалар 1891 елда булган ачлык күренешләрен сурәтләү белән башланып китә. Шуны әйтергә кирәк, романда тарихи вакыйгалар төгәл һәм дөрес сурәтләнгән.

Романдагы Тигәнәле исемле татар авылында да ачлык хөкем сөрә. Авыл кырларының пейзажлары ярлы игенче өстенә килгән бу зур бәлане күрсәтеп тора: *“Ерак чүлләрнең эссе сулышын алып килгән коры җилләр, әкияттәге пәри туен хәтерләтеп, иләмсез чиныйлар. Җиде юл чатларында, тузан баганалары күтәреп, өермәләр бөтерелә. Кырлар буенча йомарланып бүре уты тәгәри. Тын куыргыч тузанлы җил ара-тирә шундый көчәеп китә, күк йөзе карындык белән томалап куйгандай караңгылана. Кояш исә еракта-еракта, бөркү томан эчендәге маяк утына охшап, сүрән генә җемелди... Хәзер инде нишләсәң дә соң, киләсе афәт килгән. Яз башыннан бирле дым әсәре күрмәгән басулардан кисәү исе аңкытып, ком бураны гына тузгый”* [3, б.43].

Автор тарафыннан сурәтләнгән иске авыл тормышының бөтен фаҗигале хәле укучы күз алдына килеп баса. Ачлык һәм корылык күренешләре үзләренең дәһшәтле, куркыныч дөреслекләре белән тетрәтеп җибәрә. Сурәтләүләр шулкадәр төгәл бирелә, җөмлә саен үсә барган динамика, эмоциональ көч, хәрәкәт, яңадан-яңа, оригиналь чагыштырулар барлыкка килә. Иң мөһиме, бер генә артык яки урынсыз сүз дә юк!..

Романда вакыйгаларның төп өлеше 1905 – 1907 еллардагы Беренче рус инкыйлабы белән 1917 елгы Бөек Октябрь социалистик инкыйлабы арасындагы Казан пролетариаты алып барган революцион көрәш тарихына бәйле рәвештә

бара. Романда ачыктан-ачык татар халкының революцион аңы үсүе, егерменче йөз башы җәмгыятенең катлаулы сыйнфый каршылыклары, татар һәм рус пролетариатының патша самодержавиесенә һәм буржуазиягә каршы бер сафта торып көрәшүе төп проблемалар булып тора[1, б.43].

Шунысы әһәмиятле, әдип сурәтләнгән чорга хас нечкә детальләрне дә оста итеп язган һәм романның сюжет сызыкларын, шулар ярдәмендә төп образларны көрәш вакыйгалары белән тыгыз бәйләнештә сурәтли. Мостафа, Нәсимә, Саимә, Гәрәй кебек эшчеләрнең булган иң уңай сыйфатлары революцион вакыйгаларда ачылыш таба. Шушы зур тарихи чорны, иҗтимагый-политик тормышын, революцион хәрәкәт тарихын бик озак еллар дәвамында игътибар белән өйрәнү әдипне илдәге төрле милләт хезмәт ияләренең туганнарча дуслыгын дөрес чагылдыруга китергән. Чынлыкта да, романда халыклар дуслыгы идеясе күзгә ташлана һәм аның дөрес чагылышы революцион хәрәкәт белән тыгыз бәйләнгән. Романда тормыштагыча, революцион хәрәкәт төрле милләт хезмәт ияләренең үзара берләшү ноктасы булып тора, әлбәттә алар арасында булган дуслыкның җимерелмәс нигезе буларак бирелә...

“Язгы җилләр” романында төп образ булып – Мостафа образы бирелә. Мостафа образы аша автор яңа гына пролетариатлашкан крестьян вәкиленең революциягә килү юлын күрсәтә. Мостафа – Кави Нәҗми иҗатында булган төп теманы – татар халкының социалистик революциягә килүе темасын ачуда иң көчле итеп эшләнгән реалистик образ булып тора.

Искә алырга кирәк, В.И. Ленин 1905 елгы революция чорының политик шартлары турында: *“Изелгән, урта гасыр торгынлыгында кыргыйланган йөз миллионнарча халык яңа тормышка, кешелекнең иң гади хокуклары өчен, демократия өчен көрәшкә уянды”*, - дип язды [4, б.51].

Әйтергә кирәк, 1917 елның Октябрь көннәрендә Казан Кремлен штурмлау вакытында үлем җәрәхәте алган Мостафаның кызыл байракны малае Гәрәйгә тапшырырга теләве бик символик. Аның үлем алдыннан булган бу соңгы

үтенече романда*“Сәүбәновлар нәселенең революцион намусын кер кундырмый сакларлык улы барлыкка горурлану тойгысы”* булып яңгырый.

Мостафа образы гади кешенең матур, кешеләргә үрнәк булырдай образын тудыруда зур адым булып тора. Аны, һич икеләнүсез, К. Нәҗми әсәрләрендә бирелгән художестволы образларның иң көчлесе дип атарга мөмкин.

Романда, шулай ук, *гади кеше – эшче тормышы* мөһим урын алып тора. Татар, рус кешеләре бергә укмашып яшиләр, көн күрәләр. Әлбәттә, Кави Нәҗми чор таләпләренә туры китереп, эшчеләр, хезмәтчеләр тормышын күңелсез тасвирлый, ягъни, интернациональ дуслыкка басым ясый. Гади кеше – киң күңелле, кешелекле, рухи бай кеше итеп тәкъдим ителә. Мостафа белән Андрей, Гәрәй белән Гриша, Саимә исә, чуваш Егорны ярата... Ягъни, әйтергә кирәк, милли түгел, сыйнфый аерымлык, яки сыйнфый бердәмлек шәхесара мөнәсәбәтләрне билгеләп тора.

“Язгы җилләр” романында сурәтләнгән буржуазия вәкилләре арасында – Юныс бай образы нык итеп эшләнгән. Фабрикант, эре сәүдәгәр – Юныс Вәлишин үзенең байлыгын үстерү юлында бернинди пычраклыклар алдында да тукталмый, ягъни ул бары тик үз гаиләсенең яхшы, бай, мул тормышы турында гына кайгырта. Шунысын әйтергә кирәк,, Вәлишин, милләт турында кайгырткан булып, милләт берлеге, культура турында акыл сатарга бик тә ярата һәм үзен ничек кенә булмасын, либерал итеп күрсәтергә тырыша. Ләкин, болар барысыда аның намуссызлыгы, кешелексезлеге белән бик тигез аралашалар. Аның милләт өчен “борчылулары” да үзенең максатларына ирешү өчен генә: “*Бу байлыкның, әлбәттә, милләткә дә файдасы тиде. Зәкят өлешеннән милләт өчен бер мәчет, бер мәдрәсә һәм мөселманнар өчен бер кечкенә шифаханә ачтык. Сәүдәбезнең бәрәкәтле булуы һәр даим милләтне кайгыртуга баглы икәнен мин бер сәгатькә дә онытмадым...*” – ди ул [3, б.24].

“Язгы җилләр” язылу вакытының бер таләбе шундый чагылыш таба – язучы әледән-әле Ленинның иң якын ярдәмчесе, юлдашы буларак Сталинны искә ала. Чынлыкта исә, ул вакытларда Ленин бик күренекле кеше булган.

Сталинны искә алсак, ул күбесенчә “уголовник” буларак билгеле. Кави Нәҗми язуына ышансаң, инкыйлабны ике генә кеше ясаган – Ленин һәм Сталин.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк, әлбәттә татар язучысының романы, үз вакытында, үзе сурәтләгән эпохасы һәм романдагы геройлары белән беррәттән, күтәрелгән идеяләр һәм аларның сәнгатьчә чишелеше ягыннан да, күп милләтле совет әдәбиятында инкыйлаби теманы ачу, халыклар дуслыгы идеяләрен тагын да киңрәк чагылдыру кирәк икәнлеген, ачык итеп күрсәткән яңача әсәр итеп кабул ителде.

## Литература


1. Ганиева Р. Каршылыклы еллар авазы // Казан утлары. – 1983. – № 6. – Б. 177 – 179.
2. Гыйззәтуллин Н. Кави Нәҗми: тәнкыйди-биографик очерк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. – 88 б.
3. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Том 3: XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 600 б.
4. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Том 5: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941 - 1960). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 544 б.